проект

2025 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап хакында

2025 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турындагы хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турындагы хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшенең югары нәтиҗәлелеген билгеләп үтәргә, закон проекты эшчәнлеге һәм экспертиза-аналитика чаралары үткәрү өлешендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән үзара эшчәнлекнең үтемле булуын ассызыкларга.

3. Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмәләрне үз вакытында әзерләүне.

3.2. Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын формалаштыруга аудит үткәрүне.

3.3. Тикшереп тору чараларын үткәргәндә бюджет акчаларыннан, дәүләт мөлкәтеннән файдаланганда аеруча очрый торган хокук бозуларга һәм җитмәүчелеккә, коррупция куркынычларына игътибар итүне һәм хокук бозулар булмасын өчен тиешле мәгълүматны үз вакытында бюджет процессында катнашучыларга җиткерүне.

3.4. Татарстан Республикасы Хисап палатасының тикшереп тору чаралары барышында ачыкланган системалы төстәге хокук бозуларның һәм җитешсезлекләрнең сәбәпләрен анализлауны дәвам итүне.

3.5. Татарстан Республикасының бюджет кредитлары буенча бурыч йөкләмәләрен үз вакытында үтәүне, шулай ук Татарстан Республикасы

бюджетыннан бирелгән хисаплашуларны үз вакытында кире кайтаруны тикшереп торуны тәэмин итүне.

3.6. Норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү һәм норматив хокукый актларны камилләштерү буенча бюджет процессының сыйфатын арттыруга юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерләү эшен дәвам итүне.

3.7. Илкүләм проектларны, Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруга, шул исәптән аларның составы, план күрсәткечләре күләме һәм гамәлгә ашыру нәтиҗәләре үзгәрүне исәпкә алып, мониторинг ясауны.

3.8. Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен анализлау кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны финанслау күләмен, бу программаларның күрсәткечләренә һәм чараларына корректировка кертелмәгәндә, дәлилләнмәгән үзгәртү фактларын ачыклауны.

3.9. Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенә квартал саен мониторинг ясауны дәвам итүне.

3.10. Тышкы муниципаль финанс тикшереп торуын алга таба арттыру максатларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарына ярдәм күрсәтүне дәвам итүне.

3.11. Илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны мониторинглау кысаларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын белән уртак тикшереп тору һәм экспертиза-аналитика чаралары уздыруны.

3.12. Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан контроль чаралар уздыру барышында ачыкланган җитешсезлекләр һәм хокук бозулар турында мәгълүматны квартал саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру эшен дәвам итүне.

3.13. Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлегенең ачыклыгын, аның тарафыннан әзерләнә торган материаллардан һәркем файдалана алуны тәэмин итү эшен дәвам итүне.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Хисап палатасы 2026 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мәгълүмат тапшырырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы